# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасында
хезмәтне саклау турында

Әлеге Закон хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау хокукларын гамәлгә ашыруның гарантияләрен билгели һәм хезмәтне саклау өлкәсендә оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, оешмалардагы эш бирүчеләр белән хезмәткәрләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуның бердәм тәртибен тәэмин итә, хезмәт эшчәнлеге барышында һәм аңа бәйле рәвештә хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган эш шартлары булдыруга юнәлдерелгән.

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Төп терминнар һәм билгеләмәләр

Хезмәтне саклау - хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-кисәтү, савыктыру һәм башка чараларны үз эченә алган, хезмәт эшчәнлеге барышында хезмәткәрнең тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү системасы ул.

2 статья. Хезмәтне саклау турында законнар һәм аларның гамәлдә булу даирәсе

Хезмәтне саклау турындагы законнар Татарстан Республикасы

Конституциясенең тиешле нигезләмәләреннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларыннан гыйбарәт.

Әлеге Закон:

теләсә кайсы оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга (алга таба "оешмалар");

эш бирүчеләргә;

эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнарга;

оешмаларда эшләү өчен җәлеп ителгән, шулай ук җитештерү практикасы узган төрле рәвешләрдә һәм төрләрдә белем алучы студентларга, укучыларга;

оешмаларга эшкә җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләргә;

оешмаларда эшләү чорында хөкем карары буенча җәза үтәүчеләргә кагыла.

Әгәр халыкара шартнамәләрдә (килешүләрдә) башкача каралмаган булса, Татарстан Республикасының хезмәтне саклау турындагы законнары Татарстан Республикасы оешмаларында эшләүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыклары булмаган затларга кагыла.

<u>3 статья.</u> Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре

Хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, үзләренең тиешле органнары аша эш бирүче берләшмәләренең, һөнәр берлекләренең һәм хезмәткәрләр тарафыннан вәкаләт бирелгән башка вәкиллекле органнарның хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту, җитештерүдәге имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтүдә бергәләп эш итүләрен күздә тота.

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре түбәндәгеләр:

оешманың җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәләренә караганда эш башкаручыларның тормышын һәм сәламәтлеген саклауның өстенлеген тану һәм тәэмин итү;

җитештерүдә хезмәт иминлегенең югары дәрәҗәсенә ирешүгә һәм бәхетсезлек очракларын кисәтүгә ярдәм итүче норматив хокукый актлар кабул итү;

хезмәткәрләрнең имин һәм сәламәт хезмәт шартларына хокукларын яклау;

хезмәтне саклау өлкәсендә, шулай ук табигать мохитен саклау өлкәсендә эшчәнлекне икътисадый һәм социаль сәясәтнең башка юнәлешләре белән яраштыру;

оешмалар өчен үтәлеше мәҗбүри булган хезмәтне саклау буенча бердәм норматив таләпләр урнаштыру;

хезмәт шартларына экспертиза уздыруны, хезмәтне саклау турындагы законнарның һәм башка норматив хокукый актларның үтәлүенә күзәтчелек итүне һәм аны тикшереп торуны да кертеп, хезмәтне саклау өлкәсе эшчәнлегенә дәүләт идарәсе;

хезмәтне саклау өлкәсендә эш башкаручыларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүдә һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән башка вәкиллекле органнар аша гамәлгә ашырыла торган җәмәгать контроленә ярдәм итү;

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе органнарының үзләренең тиешле органнары йөзендә эш бирүчеләр, һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән, хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм аны тормышка ашыру белән кызыксынган башка вәкиллекле органнар белән үзара бәйләнеше һәм хезмәттәшлеге;

эш бирүчеләргә хезмәткәрләрне имин эш алымнарына өйрәтүне, оешмалардагы хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау кагыйдәләрен, нормаларын һәм күрсәтмәләрен белүләрен тикшерүне оештыруда ярдәм итү;

уңайлы һәм имин эш шартлары булдыру, хәвефсез техника һәм технологияләр, хезмәткәрләр өчен күмәк һәм шәхси саклану чаралары эшләү һәм гамәлгә кертү эшчәнлеген икътисадый кызыксындыру;

эш бирүчеләр һәм аларны белдерүче урындагы затлар хезмәтне саклау буенча норматив таләпләрне бозган очракларда иктисадый, административ һәм җинаять җаваплылыгы санкцияләре куллану;

җитештерүнең техник дәрәҗәсенең һәм хезмәтне оештыруның хәзерге торышы кимчелекләрне бетерү мөмкинлеген бирмәгәндә, авыр эшләр башкарган, зарарлы һәм (яисә) хәвефле шартларда эшләгән өчен компенсацияләр һәм ташламалар билгеләү;

оешмаларда хезмәт шартлары һәм иминлеге торышын даими бә-

274

яләүне үткәрү;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән яисә һөнәри авыру алган хезмәткәрләрнең, шулай ук аларның гаиләләренең мәнфәгатьләрен яклау;

хезмәткәрләрне эш бирүче хисабына махсус кием-салым, аяк киеме, күмәк һәм шәхси саклану чаралары, дәвалау-профилактика туклануы, кирәкле кисәтү чаралары белән тәэмин итү тәртибен һәм нормаларын билгеләү;

җитештерүдә бәхетсезлеккә юлыккан һәм һөнәри авыру алган һәр очракны тикшерү тәртибен билгеләү;

хезмәтне саклау өлкәсендә, шул исәптән югары һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә, шулай ук аларны әзерләү хокукына лицензиясе булган учреждениеләрдә белгечләр әзерләү;

эш шартлары, җитештерүдә бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар, алардан килгән матди зыяннар турында дәүләтнең статистика хисабын булдыру;

хезмәтне саклау өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру;

хезмәтне саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек.

## П бүлек. Эш башкаручының хезмәтне саклауга хокук гарантияләре

<u>4 статья.</u> Эш башкаручының хезмәтне саклауга хокукы

Эш башкаручы хезмәтне саклауга хаклы, шул исәптән:

җитештерүдә имгәнүгә, җитештерү аркасында килеп чыккан яисә һөнәри авыруга китерү ихтималы булган хәвефле һәм (яисә) зарарлы эш шартлары йогынтысыннан азат булган, билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән эш урынына;

эш бирүчедән, тиешле дәүләт һәм җәмәгать органнарыннан эш урынындагы хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышы турында, тиешле шәхси һәм күмәк саклану чаралары, авыр эшләр өчен, зарарлы һәм (яисә) хәвефле шартларда эшләгән өчен ташламалар, компенсацияләр хакында, сәламәтлеккә килергә мөмкин зыян турында, шулай ук зарарлы һәм (яки) хәвефле җитештерү факторлары йогынтысыннан саклану буенча чаралар күрелүе хакында дөрес мәгълүмат алырга;

башта ук (эшкә урнашканда) һәм алга таба даими медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча үз сәламәтлеге торышы хакында мәгълүмат алырга;

үзенең эш урынындагы хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшыртуга бәйле мәсьәләләрне карауда катнашырга;

эш бирүче хисабыннан хезмәтне саклау буенча законнар һәм башка норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә шәхси һәм күмәк саклану чаралары белән тәэмин ителүгә;

тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янау очрагы булганда, әлеге куркыныч юкка чыгарылганчы, эшләүче гаебе аркасында булмаган эштән туктап тору вакыты өчен билгеләнгән түләү тәртибе буенча эше өыен түләнгәнче эшләмәскә;

дәүләт күзәтүе һәм контроле, җәмәгать контроле органнарының, эш урынында, эш шартларын һәм хөзмәтне саклауның торышын тикшерүне үткәрү турында таләпкә;

эш шартлары һәм хезмәтне саклауның торышы канәгатьләнерлек булмауга бәйле рәвештә дәүләт идарәсенең тиешле органнарына, шулай ук һөнәр берлекләренең тиешле органнарына һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән башка вәкиллекле органнарга шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

эш бирүче бәхетсезлек очрагы турында акт төзүдән баш тартса яисә зыян күрүче актта бәян ителгән бәхетсезлек очрагы һәм аның сәбәпләре белән килешмәсә, дәүләт идарәсенен хезмәтне саклау, күзәтү һәм тикшереп тору органнарына мөрәҗәгать итәргә;

эш бирүче акчалары хисабына имин эш алымнарына һәм ысулларына өйрәнергә;

оешманың (аның структур бүлекчәсенең) җитештерү эшчәнлеген туктатып торганда яисә тыйганда яки зарарлы һәм (яисә) хәвефле эш шартлары аркасында эш урыны бетерелгәндә, шулай ук җитештерүдәге бәхетсезлек очрагына яисә һөнәри авыруга бәйле рәвештә эшкә сәләтсез булып калганда, эш бирүче хисабына яңа һөнәргә өйрәнергә;

эш урынында авырып киткән, имгәнгән яисә сәламәтлегенә башкача зыян килгән очракта дәвалау учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә эш бирүче транспортыннан файдаланырга;

имгәнгәндә, һөнәри авыру белән чирләгәндә яисә хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә сәламәтлекләре какшаганда

килгән зыянны түләттерергә;

сәламәтлекләре какшаганда эш бирүче хисабыннан чиратсыз медицина тикшерүе үтәргә.

5 статья. Эш башкаручының хезмәтне саклауга хокук гарантияләре

Дәүләт үзенең хакимият органнары йөзендә хезмәт процессында эш бирүче белән төзелгән шартнамә (контракт) буенча катнашучы хезмәткәргә суд тәртибендә үзенең хезмәт хокукларын яклауны гарантияли.

Эшләүчеләрнең хезмәтне саклауга хокук гарантияләре, зарарлы һәм (яисә) хәвефле шартларда эшләгән өчен компенсацияләрнең һәм ташламаларның төрләре, шулай ук аларны бирү тәртибе һәм шартлары тиешле законнар, башка норматив хокукый актлар, хезмәт шартнамәләре (контрактлары) белән билгеләнә.

Хезмәт шартнамәсенең (контрактының) шартлары хезмәтне саклау турындагы законнарның һәм башка норматив хокукый актларның таләпләренә туры килергә тиеш. Хезмәт шартнамәсендә (контрактында) эш шартларының дөрес тасвирламалары, эшләүчеләргә авыр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле эш шартлары өчен компенсацияләр һәм ташламалар күрсәтелә.

Хезмәткәрнең гаебе булмыйча, хезмәтне саклау буенча законнар һәм норматив таләпләр бозылганда дәүләтнең күзәтү һәм контроль тору органнары эшләрне туктатып торган вакытта, хезмәткәрнең эш урыны һәм эш хакы сакланырга яисә аның ризалыгы белән алдагы эштә алган уртача хезмәт хакыннан ким булмаган түләүле эш тәкъдим ителергә тиеш.

Оешманың яисә аның структур бүлекчәсенең җитештерү эшчәнлеге хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтүе һәм контроле органнары күрсәтмәсе буенча эш бирүче оешмадагы яисә аның структур бүлекчәсендәге җитештерү эшчәнлеген туктатып торганда, ул хезмәткәргә белгечлегенә туры килердәй яңа эш урыны бирергә яисә хезмәткәрне яңа һөнәргә өйрәтү чорына уртача хезмәт хакын саклап, яңа һөнәргә (белгечлеккә) түләүсез өйрәтүне тәэмин итәргә тиеш.

Хезмәткәрнең тормышына һәм сәламәтлегенә хезмәт шартнамә-

сендә (контрактта) каралмаган эшне үтәгәндә турыдан-туры куркыныч янаган, шулай ук аны шәхси һәм күмәк саклану чаралары белән тәэмин итмәгән очракта эшләүче эштән баш тартса, эш бирүче хезмәткәргә, куркыныч беткәнче, башка эш тәкъдим итәргә тиеш. Объектив сәбәпләр аркасында башка эш бирү мөмкин булмаса, хезмәткәрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янау беткәнче туктап тору вакыты хезмәткәр гаебеннән тыш туктап торгандагыча түләнә.

Тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаган очракта хезмәткәр эштән яисә хезмәт шартнамәсендә (контрактта) каралмаган авыр, зарарлы һәм (яки) хәвефле шартларда эшләр башкарудан баш тартканда, аңа карата нинди дә булса нигезләнмәгән җәза чарасы күрелми.

<u>6 статья.</u> Авыр эшләргә, зарарлы һәм (яки) хәвефле эш шартларына чикләүләр

Хатын-кызларны, унсигез яшькә җитмәгән затларны, шулай ук әлеге эшләрне башкару сәламәтлекләренә ярамаган затларны да авыр, зарарлы һәм (яки) хәвефле хезмәт шартлары булган эшләргә җәлеп итү тыела.

Татарстан Республикасы территориясендә хатын-кызларны һәм унсигез яшькә җитмәгән затларны җәлеп итү тыелган авыр эшләрнең, зарарлы һәм (яки) хәвефле хезмәт шартлары булган эшләрнең, Россия Федерациясендә гамәлдә булган исемлеге кулланыла.

Үзләренең тиешле органнары йөзендә эш бирүчеләр берләшмәләре, һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән башка вәкиллекле органнар белән консультацияләрне истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мондый эшләр исемлеген тулыландырырга хокуклы.

Эшләүчедә җитештерү өлкәсендәге зарарлы йогынты нәтиҗәсендә һөнәри авыру яисә сәламәтлеге какшау билгеләре ачыкланганда, медицина тикшерүенә таянып, эш бирүче аны законнар нигезендә башка эшкә күчерергә тиеш.

278

## Ш бүлек. Хезмәтне саклауны тәэмин итү

7 статья. Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе

Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашырудан, бу өлкәдә законнар һәм башка төрле норматив хокукый актлар эшләүдән, шулай ук хезмәткәрләргә сәламәт һәм имин эш шартлары гарантияли торган җитештерү чараларына, технологияләргә һәм хезмәтне оештыруга карата булган таләпләрдән гыйбарәт.

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты хезмәтне саклауга дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра.

Хезмәтне саклау турында Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты раслаган норматив хокукый актлар Татарстан Республикасы территориясендә министрлыклар, комитетлар, ведомстволар тарафыннан катгый үтәлергә тиеш.

8 статья. Хезмәтне саклау идарәсе органнары компетенциясе

Министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар, оешмалар хезмәтне саклауга идарә итү һәм хезмәтне саклау эшләрен оештыру өчен:

үз структураларында хезмәтне саклау эшчәнлекләре (службалары) төзиләр;

хезмәтне саклау өлкәсендә эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгелиләр, дәүләт сәясәтен һәм законнарны гамәлгә ашыру буенча чаралар күрәләр;

тармакка караган нормалар, кагыйдәләр, үрнәк күрсәтмәләр эшләүдә катнашалар, җитештерү һәм санитария-көнкүреш ихтыяҗлары өчен хезмәт итә торган объектларның төзелеш һәм реконструкция проектларына, яңа технология процессларының һәм җиһазларның санитария-гигиена һәм куркынычсызлык таләпләренә җавап бирүенә экспертиза уздыруны тәэмин итәләр;

оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча укуларын һәм белемнәрен тикшерүне оештыралар.

9 статья. Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары компетенциясе

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт хакимиятенең җирле органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

тиешле территориядә хезмәтне саклау программасын карау һәм раслау;

хезмәтне саклау турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору.

Җирле администрацияләр, җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

тиешле территориядә хезмәтне саклау программаларын әзерләү;

хезмәтне саклауны тәэмин итүдә икътисадый механизм эшләүдә катнашу;

оешмаларда хезмәтне саклауны тәэмин итү турында эш бирүчеләрнең хисапларын тыңлау.

10 статья. Оешмада хезмәтне саклау

Оешмада законнар нигезендә хезмәтне саклау эшчәнлеге (службасы) төзелергә мөмкин.

Хезмәтне саклау эшчәнлеге вазыйфаларын тиешле әзерлеге булган (укыган) затлар яисә җитәкчеләрнең берәрсе башкара ала. Оешма хезмәткәрләренең бу вазыйфаларны башкару мәмкинлеге булмаганда, эш бирүче консультацияләр бирү һәм сервис хезмәте күрсәтү өчен башка оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хезмәтне саклау буенча белгечләрен җәлеп итә.

Хезмәтне саклау эшчәнлеге турыдан-туры эш бирүчегә яисә аның кушуы буенча башка урындагы затка буйсына.

Хезмәтне саклау эшчәнлеге белгечләре структур бүлекчә җитәкчеләренә һәм урындагы затларга кимчелекләрне бетерү буенча үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә, алардан хезмәтне саклау мәсьәләләре турында тиешле белешмәләр һәм мәгълүматлар, документация, аңлатмалар (язмача да) алырга, медицина тикшерүе узмаган, укымаган, инструктаж һәм белемнәрен тикшерүләрне узмаган, укымаган, инструктаж һәм белемнәрен тикшерүләрне узмаган һәм шул эшкә кушылмаган, шәхси саклану чаралары куллан-

280

маган яисә хезмәтне саклау таләпләрен үтәмәгән затлардан эштән китүләрен таләп итәргә хаклы.

Хезмәтне саклау эшчәнлеге белгечләре, хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырган очракларда җитештерү урыннарында, участокларда эшләрне туктатырга, машиналарның, станокларның, җиһазларның һәм башка җитештерү чараларының, завод эчендәге транспорт чараларының эшен туктатырга, хезмәтне саклау таләпләрен бозучы урындагы затны җаваплылыкка тарту турында эш бирүчегә күрсәтмә бирергә хаклы.

Оешмада бертигез дәрәҗәдә эш бирүче вәкилләре, һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле башка вәкилләре катнашында хезмәтне саклау буенча уртак комитет (комиссия) төзелергә мөмкин, аның карары тәкъдим итү көченә ия.

<u>11 статья.</u> Сәламәт һәм имин хезмәт шартлары белән тәэмин итү буенча эш бирүченең бурычлары

Оешмада хезмәт шартлары торышы өчен җаваплылык эш бирүчегә йөкләнә.

Эш бирүче түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

оешмада хезмәтне саклау эшчәнлеген төзүне;

җитештерү биналарын, корылмаларны, җиһазларны эксплуатацияләүдә иминлекне, технологик гамәлләрнең, җитештерүдә кулланыла торган чимал һәм материалларның иминлеген, шулай ук күмәк һәм шәхси саклану чараларының нәтиҗәле кулланылуын;

хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләүне, оешманың җитештерү объектларының хезмәтне саклау таләпләренә туры килүен сертификацияләүне;

эшләүчеләргә тиешле санитария-көнкүреш һәм дәвалау-кисәтү хезмәте күрсәтүне оештыруны;

законнарда каралган тәртиптә хезмәткәрләрнең хезмәтен һәм ялын оештыруны;

хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау турында норматив хокукый актлар таләпләрен үтәвен тикшереп торуны;

зарарлы һәм (яисә) хәвефле эш шартлары булган эшләрдә, шулай ук пычрануга бәйле эшләрдә эшләүчеләр өчен билгеләнгән нормалар нигезендә бушлай махсус кием-салым, аяк киемнәре, башка шәхси саклану чаралары, юу һәм зарарсызландыру әйберләр

281

бирүне;

зарарлы һәм (яки) хәвефле эш шартларының хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә ни дәрәҗәдә тәэсир итүен нәтиҗәле тикшереп торуны;

хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә имгәнгән, һөнәри авыру алган яисә башкача сәламәтлеген югалткан хезмәткәрләргә килгән зыянны кайтаруны;

хезмәткәрләрне укыту, инструктаж үткәрү, аларның хезмәтне саклау буенча нормаларны, кагыйдәләрне һәм күрсәтмәләрне белүләрен тикшерү, шулай ук җиһазларны урнаштыру һәм куркыныч янаган объектлардан хәвеф-хәтәрсез файдалану кагыйдәләре буенча җаваплы затларны әзерләүне һәм аларның белемнәрен күтәрүне;

билгеләнгән тәртиптә хезмәтне саклау кагыйдәләрен, нормаларын һәм күрсәтмәләрен өйрәнү, белү дәрәҗәсе тикшерелмәгән, инструктаж узмаган затларны эшкә җәлеп итмәүне;

эш урынындагы шартлар һәм хезмәтне саклауның торышы, сәламәтлеккә килергә мөмкин зыян һәм хезмәткәрләргә бирелергә тиешле шәхси саклану чаралары, компенсацияләр һәм ташламалар хакында хезмәткәрләргә мәгълүмат бирүне;

оешмада эш шартларын һәм хезмәтне саклауның торышын, хезмәтне саклау хакында законнарның үтәлешен, шулай ук эштә бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны тикшерү өчен хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, дәүләт күзәтү һәм контроль органнары вәкилләрен тоткарлыксыз үткәрүне;

һәлакәт очраклары килеп чыкканда, хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, шул исәптән зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү буенча тиешле чаралар күрүне;

тиешле тәртиптә расланган нигезләмәләр җирлегендә эштәге бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны тикшерүне;

эштәге бәхетсезлек очрагы турындагы актның расланган нөсхәсен, аны тикшерү тәмамлаганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча, зыян күргән хезмәткәргә тапшыруны;

хезмәтне саклау өлкәсендәге дәүләт идарәсе органнарына, дәүләт күзәтүе һәм контроле органнарына, хезмәтне саклау турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торучы җәмәгать органнарына оешмадагы эш шартлары һәм хезмәтне саклауның торышы хакында бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан иминләштерелүченең кертемнәрне үз вакытында түләве хакында, шулай

282

ук хезмәтне саклау өлкәсендә законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозган өчен дәүләт күзәтүе һәм контроле органнары салган штрафлар хакында, шулай ук эштә теркәлергә тиешле барлык бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар хакында тиешле мәгълүмат бирүне;

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтүе һәм контроле органнарының үз вәкаләтләре кысаларында кабул ителгән күрсәтмәләрен үтәүне;

хезмәткәрләрне авыру сәбәпле вакытлыча эшләми торудан, шулай ук эш урынындагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри иминләштерүне.

<u>12 статья.</u> Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрнең бурычлары

Эш башкаручы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

үзенең һәм башка эшләүчеләрнең сәламәтлегенә зыян китерми торган имин эш күнекмәләрен белергә, үз эшчәнлеге өлкәсенә караган хезмәтне саклау турында закон таләпләрен белергә һәм үтәргә;

хезмәтне саклау нормаларын, кагыйдәләрен, күрсәтмәләрен үтәргә, эшне төзек булмаган техник җитештерү чараларында һәм җиһазларда башкармаска;

билгеләнгән тәртиптә хезмәтне саклау буенча өйрәнү, инструктаж һәм белемнәрне тикшерүне узарга;

шәхси һәм күмәк саклану чараларын дөрес кулланырга:

махсус кием-салым, махсус аяк киеме киеп эшләргә, әгәр кагыйдәләрдә һәм күрсәтмәләрдә каралган булса, шәхси, күмәк саклану чараларыннан файдаланырга;

эш урынындагы һәр бәхетсезлек очрагы, шулай ук кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган теләсә нинди хәл хакында кичекмәстән үзенең турыдан-туры җитәкчесенә хәбәр итәргә;

законнарда каралган очракларда медицина тикшерүе узарга һәм аның нәтиҗәсе буенча әйтелгән киңәшләрне үтәргә;

хезмәтне саклау турында законнарны үтәүдә эш бирүченең һәм күзәтү, контроль гамәлләрен башкаручы затларның башка законлы таләпләрен үтәргә.

13 статья. Медицина тикшерүләре

Эш бирүче үз хисабына, законда каралган очракларда, оешма хезмәткәрләренең үзләренә йөкләнгән эшкә яраклылыгын ачыклау һәм һөнәри авыруларны кисәтү өчен башлангыч (эшкә урнашканда) һәм даими рәвештә (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүе узуларын оештырырга тиеш. Эш башкаручы медицина тикшерүе узудан баш тартканда яки тикшерү нәтиҗәләре буенча киңәшләрне үтәмәгәндә эш бирүче аны хезмәт вазыйфаларын башкаруга җәлеп итмәскә тиеш.

14 статья. Хезмәтне саклау буенча укыту һәм күрсәтмәләр бирү

Эшкә яңа керүче, шулай ук башка эшкә күчерелә торган затлар өчен эш бирүче хезмәтне саклау буенча инструктаж уздырырга, хәвефсез эш алымнарына һәм ысулларына өйрәтергә бурычлы.

Зарарлы һәм (яки) хәвефле эш шартлары булган урынга эшкә керүче затлар өчен хезмәтне саклау буенча башлангыч укыту оештырыла, алардан имтихан алына һәм соңрак алар даими рәвештә аттестацияләнеп торалар.

Җитәкчеләрне дә кертеп, оешманың барлык хезмәткәрләре инструктаж, уку-өйрәнү узарга, хезмәт куркынычсызлыгы буенча кагыйдәләрне, нормаларны һәм күрсәтмәләрне белүгә тикшерү үтәргә бурычлы.

15 статья. Җитештерү объектларының һәм җитештерү чараларының хезмәтне саклау таләпләренә туры килүе

Җитештерү объектларын проектлаганда, төзегәндә һәм төзекләндергәндә, машиналар, механизмнар төзегәндә, технология процесслары, шәхси һәм күмәк саклану чаралары эшләгәндә хезмәтне саклау таләпләре үтәлергә тиеш.

Чит илдән алган машиналар, станоклар, механизмнар, җиһазлар, транспорт чаралары, шәхси һәм күмәк саклану чаралары, технология процесслары, материаллар һәм химик матдәләр Россия Федерациясендә билгеләнгән хезмәтне саклау таләпләренә туры килергә һәм иминлек сертификатына ия булырга тиеш.

Җитештерү объектларының һәм җитештерү чараларының проектлары хезмәтне саклау буенча норматив хокукый акт таләпләренең тулысынча үтәлешенә дәүләт экспертизасы, ә продукциянең тәҗрибә үрнәкләре аларның хезмәтне саклау буенча норматив хокукый акт таләпләренә туры килүенә дәүләт сынавы узарга тиеш.

Яңа яки төзекләндерелә торган җитештерү объектлары һәм җитештерү чаралары дәүләт экспертизасы органнары бәяләмәсеннән тыш, эш шартлары бәяләмәсеннән гайре һәм үз эшчәнлекләренең юнәлешләре буенча махсус вәкаләтле башка дәүләт күзәтүе һәм контроле органнары бәяләмәсе булмыйча, файдалануга кабул ителмиләр. Оешмаларда тиешле иминлек сертификаты рәсмиләштерелә.

<u>16 статья.</u> Зарарлы матдәләр һәм материаллар җитештергәндә һәм кулланганда хезмәткәрләрнең иминлеген тәэмин итү

Җитештерүдә ысулиятләре, метрологик контроль чаралары эшләнмәгән һәм токсикология (санитария-гигиена, медицина-биология) бәяләмәләре булмаган хәвефле һәм зарарлы химик матдәләр һәм материаллар куллану тыела.

Кеше организмына һәм сәламәтлегенә тәэсирен ачыклаучы махсус экспертиза узмаган яңа матдәләрне һәм материалларны куллануга юл куелмый.

Эшчәнлекләре зарарлы, шартлау куркынычы булган матдәләр җитештерү, куллану, саклау, төяү һәм ташу белән бәйле оешмаларда норматив-техник документлар эшләнә һәм зарарлы матдәләрнең хезмәткәрләргә тәэсирен булдырмый кала торган оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-кисәтү чаралары һәм башка чаралар уздырыла.

<u>17 статья.</u> Хезмәтне саклау буенча белгечләр әзерләү

Дәүләтнең югары һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә, шулай ук аларны әзерләү хокукына лицензиясе булган учреждениеләрдә хезмәтне саклау буенча белгечләр әзерләүне тәэмин итә. Хезмәтне саклау мәсьәләләре шулай ук башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү программаларына да кертелә.

18 статья. Хезмәт саклауны тәэмин итүнең икътисадый механизмы

Хезмәт саклауны тәэмин итүнең икътисадый механизмына түбәндәгеләр керә:

хезмәтне саклау буенча чараларны планлаштыру һәм финанслау;

эш бирүчене хезмәтне саклауның камилрәк чараларын кертүгә икътисадый кызыксындыруны тәэмин итү;

оешмада зарарлы һәм (яисә) хәвефле эш шартлары, хезмәтне саклау буенча таләпләргә җавап бирми торган җитештерү чаралары чыгарган һәм җибәргән өчен икътисадый җаваплылыкны тәэмин итү;

хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә хезмәткәрләр имгәнгәндә, һөнәри авыру алганда яки сәламәтлеге башкача зарарланганда эш бирүченең зыянны каплавы;

авыр эш башкарган, җитештерүнең һәм хезмәтне оештыруның бүгенге халәтендә бетереп булмый торган зарарлы һәм (яки) хәвефле шартларда эшләгән өчен хезмәткәрләргә компенсацияләр һәм ташламалар бирү.

19 статья. Хезмәтне саклауны финанслау

Оешмаларда (бюджетныкылардан тыш) хезмәтне саклау гамәлләрен финанслау оешмаларның үзләре хисабына, законнарда, күмәк шартнамәләрдә һәм килешүләрдә билгеләнгән күләмнәрдә башкарыла.

Бюджет оешмалары чыгымнар сметасында ел саен, министрлыкларны, дәүләт комитетларын, ведомстволарын да кертеп, хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау гамәлләрен финанслау өчен чыгымнар билгеле.

Эшләүче хезмәтне саклауга бәйле бернинди чыгымнар да тотмый.

286

20 статья. Оешмаларда хезмәтне саклау чаралары, хәвефсез технологияләр һәм җитештерү чаралары эшләп чыгару өчен икътисадый кызыксындыруны тәэмин итү

Яңа, тагын да хәвефсезрәк технологияләр һәм җитештерү чаралары булдырудан, хезмәткәрләрне шәхси һәм күмәк саклану чараларын, җитештерү өлкәсен тикшереп тору приборларын чыгарудан һәм сатудан һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге эшчәнлектән кергән табышка салым буенча оешмаларга законнарда билгеләнгән тәртиптә ташламалар бирелергә мөмкин.

## IV бүлек. Хезмәтне саклау турындагы законнарның үтәлешен күзәтү һәм тикшереп тору

21 статья. Хезмәтне саклау турындагы законнарның үтәлешенә дәүләт күзәтүе һәм контроле

Хезмәт шартлары, аны саклау, хезмәт иминлеге һәм гигиенасы буенча законнарның һәм башка норматив актларның үтәлешен дәүләт күзәтүен һәм контролен законнарда билгеләнгән тәртиптә бу органнар турындагы нигезләмәләр белән үз вәкаләтләренә караган эшчәнлек юнәлешләре буенча махсус вәкаләтле дәүләт органнары башкара.

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтүе һәм контроле органнарының аларның урындагы затларының үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарлары, оешмалар, аларның эш бирүчеләре һәм урындагы затларына үтәү өчен мәҗбүри.

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтү һәм контроль органнарының урындагы затлары үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен законнар нигезендә җаваплы була.

22 статья. Хезмәтне саклауда җәмәгать контроле

Хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга җәмәгать контролен һөнәр берлекләренең тиешле органнары һәм хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән башка вәкилллекле органнар гамәлгә ашыра, алар шушы максатларда үз

инспекцияләрен төзи алалар.

һөнәр берлекләренең яки хезмәт коллективының хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлары хезмәтне саклау өлкәсендәге дәүләт идарәсе органнары тәкъдимнәре нигезендә эшли.

Үзләренең тиешле органнары аша һөнәр берлекләре хезмәткәрләрнең хезмәтне саклауга хокукларын яклый, бу хокукларның гамәлгә ашуын тикшереп тора, хезмәтне саклау буенча законнарны һәм башка норматив хокукый актларны эшләүдә һәм килештерүдә катнаша.

Үзләренең тиешле органнары аша һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләр вәкаләт биргән башка вәкиллекле органнар түбәндәгеләргә хаклы:

эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау турында закон актларын һәм башка норматив хокукый актларны үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

оешмада эшләүчеләрнең хезмәт иминлеге шартларына бәйсез экспертиза үткәрергә;

эш урынында бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны тикшерүдә катнашырга һәм мөстәкыйль тикшерү алып барырга;

эш шартлары һәм хезмәтне саклауның торышы, шулай ук эш урынында теркәлергә тиешле бәхетсезлек очраклары хакында мәгълүмат алырга;

хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаган очракларда эшләрне туктатып тору хакында таләп куярга;

хезмәтне саклау турында закон бозулар ачыкланганда, аларны бетерү хакында һичшиксез каралырга тиешле күрсәтмәләрне эш бирүчеләргә тапшырырга;

күмәк шартнамәләрдә яки килешүләрдә каралган эш шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын тикшерергә;

бәйсез эксперт сыйфатында җитештерү объектларын һәм җитештерү чараларын сынау һәм файдалануга кабул итү буенча комиссияләр эшендә катнашырга;

хезмәтне саклау буенча норматив таләпләрне бозуда, эш урынындагы бәхетсезлек очракларын яшерүдә гаепле урындагы затларны җавапка тартуны таләп итеп, тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә;

хезмәтне саклау турындагы законнарны, хезмәтне саклау бу-

енча кумәк шартнамәләрдә яки килешүләрдә каралган йөкләмәләрне бозу, эш шартлары үзгәрүгә бәйле хезмәт бәхәсләрен хәл итүдә катнашырга хокуклы.

## V бүлек. Хезмәтне саклау буенча таләпләрне бозган өчен җаваплылык

**23 статья.** Хезмәтне саклау турында законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозган өчен эш бирүчеләрнең һәм урындагы затларның җаваплылыгы

Хезмәтне саклау турында законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозуда, хезмәтне саклау буенча кумәк шартнамәләрдә яки килешүләрдә каралган йөкләмәләрне үтәмәүдә яисә дәүләтнең күзәтү һәм контроль, шулай ук җәмәгать контроле органнары эшчәнлегенә комачаулык итүдә гаепле эш бирүчеләр һәм урындагы затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә дисциплинар, матди административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

**24 статья.** Хезмәтне саклау буенча норма таләпләренә җавап бирми торган җитештерү чаралары һәм технология проектлары эшләгән өчен, җитештерү-техник максатларда продукция чыгарган һәм җибәргән өчен оешмаларның җаваплылыгы

Хезмәтне саклау буенча норма таләпләренә җавап бирмәгән яңа технологияләр керткән, җитештерү чаралары проектлары эшләгән һәм җитештерү-техник максатларда продукция чыгарган һәм җибәргән өчен оешмалар кимчелекләрне бетерү чараларын күрергә һәм законнар нигезендә кулланучыларга китерелгән зыянны кайтарырга тиеш.

**25 статья.** Хезмәтне саклау турында законнар һәм башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозган өчен хезмәткәрләрнең җаваплылыгы

Хезмәтне саклау турында законнар һәм башка норматив хоку-

289



кый актлар таләпләрен бозган өчен оешмаларда эшләүчеләр дисциплинар җаваплылыкка, ә тиешле очракларда законнарда билгеләнгән тәртиптә матди һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

26 статья. Оешмаларның яисә аларның структур бүлекчәләренең җитештерү эшчәнлеген туктатып тору

Оешманың яисә аның структур бүлекчәләренең җитештерү эшчәнлеге хезмәткәрләрнең һәм (яисә) халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырган очракларда, хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтү һәм контроле органнары күрсәтмәсе нигезендә кимчелекләрне бетергәнчегә кадәр бу эшчәнлек туктатып торыла.

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт күзәтүен һәм контролен башкаручы органнарның оешманың яисә аның структур бүлекчәләренең җитештерү эшчәнлеген туктатып тору турындагы күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы<br>Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,<br>1997 елның 10 декабре<br>N 1417